ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7) гидротехник корылмалар, шул исәптән сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары барлыкка китерүче гидротехник корылмалар, төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү, сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары урнаштыру, елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү өчен Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы нигезендә юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен бирү;».

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 26 февраль
№ 14-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ